КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 август г.Казань № 626

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1141 нче, 2020 ел, 13 июль, 584 нче, 2021 ел, 31 май, 408 нче, 2022 ел, 11 февраль, 114 нче, 2022 ел, 10 июнь, 546 нчы, 2022 ел, 16 декабрь, 1354 нче, 2023 ел, 2 май, 549 нчы, 2023 ел, 30 май, 660 нчы, 2023 ел, 22 сентябрь, 1180 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән инвалидларны - махсус хәрби операция ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары булдыруга чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законын, «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә

ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктка «, шул исәптән инвалидларны - махсус хәрби операция ветераннарын» сүзләрен өстәргә;

3 пунктта:

икенче абзацка «инвалидлар» сүзеннән соң «, шул исәптән инвалидларны - махсус хәрби операция ветераннарын» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацка «инвалидлар» сүзеннән соң «, шул исәптән инвалидларны - махсус хәрби операция ветераннарын» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эш бирүчеләрнең инвалидларны, шул исәптән инвалидларны - махсус хәрби операция ветераннарын эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары булдыруга чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе»;

1.1 пунктта татар текстында «инвалидларны» сүзеннән соң «, шул исәптән инвалидларны - махсус хәрби операция ветераннарын» сүзләрен өстәргә;

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«эш эзләүче гражданнар - туры килә торган эш эзләү максатларында теркәлгән инвалидлар, шул исәптән инвалидлар - махсус хәрби операция ветераннары.»;

1.3 пунктның беренче абзацында «инвалидлар» сүзен «эш эзләүче гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта:

өченче абзацта «инвалидлар» сүзен «эш эзләүче гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «инвалидлар» сүзен «эш эзләүче гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның өченче абзацында «инвалидларның эш белән тәэмин ителеше» сүзләрен «эш эзләүче гражданнарның эш белән тәэмин ителеше» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның унөченче абзацында «инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота кысаларында инвалидларны» сүзләрен «эш эзләүче гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктта:

унөченче абзацта «инвалидларны эш белән тәэмин ителешен» сүзләрен «эш эзләүче гражданнарның эш белән тәэмин ителешен» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «агымдагы елга билгеләнгән квота чикләрендә төзелгән инвалидны (инвалидларны) эшкә урнаштыру» сүзләрен «эш эзләүче гражданнарны эшкә урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«N – эш эзләүче гражданнар өчен булдырыла торган махсус эш урыннары саны, әмма квота кысаларында инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш бирүчегә билгеләнгән һәм шуннан артмаган эш урыннары саны;»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Субсидия бирү нәтиҗәләре - инвалид, шул исәптән инвалид - махсус хәрби операция ветераны өчен махсус эш урыны булдыру, һәм инвалидның, шул исәптән инвалид - махсус хәрби операция ветеранының һәрбер махсус төзелгән эш урынында субсидия күчерелгән көннән алып өч еллык чорның һәр ел дәвамында эш вакытының еллык нормасының кимендә яртысында эш белән тәэмин ителешен тәмин итү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин